# Иҗтиһат итүнең бөек үрнәге

«Тарихны җиңүчеләр яза, ә хак тарихны бер Хак үзе генә белә» дигән гыйбарә бар. Дөрестән дә шулайдыр. Әмма җиңүчеләр үзләре үк тарихка керсен өчен, тарихи вакыйга булуы, ул вакыйгаларның һәм шәхесләрнең вакыт алдында сынау үтүе зарур. Татар халкының меңнәрчә еллык, берничә дәүләткә бәйле тарихында нинди генә шәхесләр булмаган. Вакыт галиҗәнаплары аларның һәркайсын хак бәяләп, үзләренә тәгаенләнгән тарих сәхифәләренә теркәп калдырган. Инде килеп, дәүләтчелеген җуйганнан соң да милли азатлыгы, хак дине өчен көрәшкән фидаиларны онытмый, үзенең хәтер сандыгына салып бара тарих.

Дәүләтчелеген югалткан татар халкы 464 ел дәвамында бер генә мизгелгә дә үзбаш булып яшәү теләгеннән ваз кичмәгән. Тарих агышында килеп чыккан һәр уңайлы очрак милли күтәрелешкә сәбәпче булган... Узган гасыр башларында СССР составында Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелсә, гасыр азагында аны уртак Ватанда тагын да вәкаләтле, хокуклы итү өчен көрәшеп, мөстәкыйль дәүләт итү турында Декларация кабул ителде. Татарстан Республикасының, дәүләт буларак, үз Конституциясе гамәлгә куелды. Россия Федерациясе белән вәкаләтләр бүлешү турында Килешү төзелде, халыкара мөстәкыйль бәйләнешләр хокукына ирешелде. Иң мөһиме, милли үсеш өчен яңа мөмкинлекләр ачылды. Бу тарихи вакыйгаларның башында һәркайсы үз миссиясе һәм җаваплылыгы белән дистәләрчә милләттәшләребез торды. Ә инде безнең әдәби каһарманыбыз сыйфатында тәкъдим ителгән Минтимер Шәрип улы Шәймиев шул дәвернең әйдаманы, әләмдары булып танылды... Әйе, танылды. Татар иле, бөтен дөнья җәмәгатьчелеге һәм чирек гасыр дәвамындагы вакыт сынавы белән танылды ул.

Милли әдәбиятыбызда Татарстан Республикасының беренче Президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиевнең әдәби образын иҗат итү — бүген өлгергән мәсьәлә. Илбашына багышлап моңарчы язылган очерклар, шигъри әсәрләр, җырлар аның әдәби образын тудыруда билгеле бер этап булып тора. Бигрәк тә документаль очерк жанрында аның шәхесенә генә хас сыйфатларны тасвирлаган, психологик портретын шәрехләгән, кешелеклелек сыйфатларын чагылдырган дистәләрчә уңышлы язмалар дөнья күрде. Ил күләмендә һәм Татарстанда булып үткән кантарлы вакыйгаларга бәйләп, Илбашының эчке кичерешләре, хезмәттәшләренә, гомумән, кешеләргә карата булган мөнәсәбәтләре шактый тулы яктыртылды. Әмма болар гына шәхеснең әдәби каһарман буларак җитлегү дәрәҗәсен, аның тирән тамырларыннан сутлап чыккан, үскән, ныгыган кәүсә-ябалдашының үзенчәлекле сыйфатларын тулаем чагылдыра алмый әле. Шәхеснең әдәби каһарман буларак зурлыгы да ул катнашкан тарихи вакыйгаларга никадәр тыгыз мөнәсәбәттә торуына бәйле. Илбашы булып танылган ир-атның замандашлары белән уртак һәм үзгә сыйфатлары нидә соң? Ул үзгәлек — аның ил, милләт, заман алдында зур җаваплылык тоеп, ул җаваплылыкны иңенә салу өчен үзендә әхлакый, этик сыйфатлар булдыра һәм аларны куллана белүендә, ихтыярын бер учка туплый һәм эшкә җигә алуында. Һәм иң мөһиме: үз максатына пәйгамбәрлек дәрәҗәсендәге иман ныклыгы һәм инану белән ирешүендә... Тагын бик күп сыйфатлары белән аерыла, аерылырга тиештер ул Илбашы... Әмма аерылып торган сыйфатлардан һәркемгә хас, охшаш, уртак сыйфатлар күп мәртәбәләр ишлерәк. Күбрәк, чөнки ул да җир баласы. Ул да җиргә елый-елый яшәү даулап килгән, ул да гомере буе табигый ихтыяҗларын канәгатьләндереп яши. Үзен, гаиләсен, якыннарын имин тормышта яшәтергә омтыла...

Инде «Илбашы» әсәренең үзенә килик. Иң әүвәл шуны әйтик: Илбашына багышланган мондый эпик әсәр иҗат итәрдәй язучыларыбыз, шөкер, бар безнең. Соңгы 40—50 елда гына да милли каһарманнарыбызга багышланган тарихи романнар, бәян, очерклар, сәхнә әсәрләре язган дистәләрчә әдипләребез үсеп чыкты.

Илбашы турында әдәби-документаль әсәр язарга Татарстанның халык язучысы Рабит Батулланың барыннан да өлгеррәк булып алынуы аңлашыла да. Беренчедән, ул — Минтимер Шәймиевнең замандашы, татарның ил-көнендә барган хәл-вакыйгаларны читтән күзәтүче әдип кенә түгел, ә шул вакыйгалар эчендә үзе дә кайнаган милләтпәрвәр көрәшчебез дә ич әле. Ул — мәйданнарда, митин-

гларда ялкынлы чыгышлары белән милләттәшләрнең аң-зиһенен уяткан оратор, радио-телевидение, матбугат аша йөзләгән чыгыш ясаган мәгърифәтче. Икенчедән, Р. Батулла — үз иҗат гомерендә тарихи шәхесләргә багышланган «Сөембикә-ханбикә», «Кылдан нечкә, кылычтан үткен», «Кәбир Бәкер», «Аксак Тимер», «Тукай-Апуш», «Бию җене кагылган егет» кебек романнар, дистәләрчә киносценарийлар, сәхнә әсәрләре язган тәҗрибәле, киң колачлы язучы. Әдипнең «Урыннары җәннәттә булсын» дигән, милли каһарманнарыбызга багышланган очерклары, хикәяләре тупланмасы үзе берничә томнан тора. Бер сүз белән әйткәндә, зур иҗат тәҗрибәсенә ия була торып, «Илбашы» әсәрен язарга нәкъ менә Рабит Батулла алынмаса, гаҗәбрәк тоелыр иде.

Бу урында әсәрнең ике үзенчәлеген билгеләп үтәргә кирәктер. Автор әдәби каһарманы образының никадәр олы булуын һәм аңа мөнәсәбәтле вакыйгаларны тулысынча колачлау мөмкин түгеллеген анык белә. Шуңа да карамастан ул үз героеның дөньяга килүеннән алып бүгенге көнгәчә тормыш юлын эзлекле рәвештә хикәяләп барырга тырыша. Менә шул хикәяләү ысулы, стиле аңа документаль-нәфис жанрдагы эпик әсәр язарга ярдәм итә дә. Шундый 70 ләп хикәя тупланган әсәр бердәм сюжет сызыгы булган бербөтен роман сыйфатында кабул ителә, ул ил-көндә тулы бер гасыр дәвамында барган вакыйгаларны колачлый. Әдәби каһарманнарның нәсел-нәсәбен, язмышларына бәйле фактларны җентекләп, тирәнтен өйрәнгән автор. Илбашының һәм аның булачак гомер юлдашы Сәкинә ханымның нәсел тамырларын барлаганда, һәр ике гаиләнең төрле дәрәҗәдә репрессиягә эләгүләрен, тормыш университетын бик яшьли үтүләрен, шул катлаулы чорның үзен шактый кырыс буяулар белән тасвирлый ул. Әсәрдә милли татар гаиләсе традицияләре, йолалары, үрнәкләре, өлкәннәр-балалар, гаилә мөнәсәбәтләре аерым хикәяләрдә каһарманнарның эш-гамәлләре аша чагылыш таба.

Китапта тупланган хикәяләрнең бер өлеше әдәби каһарманыбызның ил-көндә яшәү өчен көрәшүче, социаль җитлегү чорын кичерүче үсмер, ир-егет, гаилә башлыгы буларак тормыш юлын сурәтләүгә багышланса, бер өлеше исә берсеннән-берсе җаваплырак вазифалар башкаручы ир-атның ничек итеп күренекле тарихи шәхескә әверелә баруын бәян кыла. Бу хикәяләрдә тормышның һәр сынавын ирләрчә, аек акыл белән кабул итәргә, кичерергә, җиңеп чыгарга өйрәнгән мөстәкыйль фикер йөртүче, сәясәтче, Илбашы образы гәүдәләнә.

Әсәр белән кулъязма хәлендә танышканда ук, ил агасының кылган күп кенә тәвәккәл гамәлләре күз алдыма килеп басты. Аның үзе белән шәхсән очрашып сөйләшкәндә дә, бик күп кызыклы яңалыклар ачкан идем мин.

Гаделлек, җаваплылык тойгысы беренче чиратта гаилә тәрбиясеннән килә. Ә инде әсәр авторы искәрткәнчә, ишле гаиләдә, син тәртипле бул, син намуслы бул, дип вәгазьләүдән бигрәк, менә сиңа шундый эш, син шуны башкарып чык, дип, вазифа йөкләп, җаваплылыкка өйрәтәләр. Ишле гаиләдә олыны олы, кечене кече итү, туганлыкның кадерен белү кирәклеге канга сеңдерелә. Табында өлешнең тигез бүленүе, күмәк хезмәт күнекмәләре һәм шәхси үрнәк — болар барысы да дәүләтнең бер «күзәнәге» булган гаиләнең өстенлекле тәрбиясе. Гаиләдә тугызынчы бала булып дөньяга килгән Минтимер гаилә мәнфәгате — дәүләт мәнфәгате дә икәнен сабый чагыннан ук тоемлап үскән ләбаса.

...Минтимер Шәрип улы Актаныш элеваторын турыдан-туры үзе төзеткән дип ишеткәнем бар иде. Бер очрашуыбызда ул бу хакта үзе тагы да ачылып сөйләп алган иде.

Шәймиев мелиорация һәм су хуҗалыгы министры булып эшләгәндә, бер елны игеннәр күкрәп уңа. Тик җәй, көз бик яңгырлы килеп, урып-җыю эшләре соңара. Хуҗалыкларда ашлыкны киптерү җайланмалары җитешми. Чаллы элеваторы ерак. Минтимер ага күрше республика җитәкчеләренә аларның районга терәлеп диярлек торган элеваторына Актаныш ашлыгын салып киптерү үтенече белән мөрәҗәгать итә. Ут күршеләр исә, төрле сылтау табып, бу тәкъдимгә ризалашмый...

— Шул чакта үзем өчен дә, алар өчен дә гарьләндем, — дип искә алган иде Минтимер Шәрипович әлеге вакыйга уңаеннан.

Шул көнне үк ул Чаллыга юл тота. Үзара яхшы мөнәсәбәттәге «КамГЭСэнергострой» төзелеш берләшмәсе җитәкчесе Е. Батенчук янына кереп, хәлне сөйләп бирә... Кичекмәстән Актанышта күршеләрнекеннән ким булмаган элеватор төзергә килешә ике тәвәккәл ир-ат. Тик эшне нидән башларга — кул астында бер проект та юк лабаса. Ярый ла «КамГЭСэнергострой» ил күләмендә куәтле оешма. Үзләрендә геодезистлар да, проектчылар да бар. Шулай да Минтимер Шәрипович нинди ышандырырлык сүзләр тапкандыр да, илнең удар төзелешендәге оешманы «чит, планда каралмаган» төзелеш эшенә ничек җәлеп иткәндер? Фәкать Мәскәүдән рөхсәт алып, финансланып кына төзелә торган стратегик корылманы бер ел дигәндә төзеп бетереп файдалануга тапшыралар. Бу хакта ки-

тапта юк. Әмма аңа охшашлары җитәрлек. Мондый мөстәкыйльлек, тәвәккәллек сыйфатлары аңа Илбашы булып сайлангач, әсәрдә бәян ителгән тагы да катлаулырак сәяси мәсьәләләрне хәл иткәндә, Татарстан Республикасы, татар милләте мәнфәгатьләрен яклап, корыч калкан булып басарга ярдәм итәчәк әле.

Ә инде республикабыз халкын тузган тородктан чыгару, илдә иң беренчеләрдән булып газлаштыруны хәл итү — үзе бер эпопея... Актаныш, Мөслим, Минзәлә районнарындагы авылларны ничек газлаштыруның шаһиты үзем ләбаса...

Әлмәт — Пермь нефтьүткәргечендәге торбаларны алыштыру вакыты җитә... Бу эшләр федераль план буенча үзәктән финанслана бит инде. Нефтьүткәргеч торбалар өр-яңа трассага салынып, янәшәдәге элекке трассада ремонт үткәрелеп, ул югарыда саналган районнарга газ үткәрү магистраленә әверелә... Һәр районга, авылларга газ торбалары сузуны республика җитәкчесе әнә шундый тәвәккәл адымнар белән хәл итә. Беренче елны ук мәктәп, балалар бакчасы, хастаханәләр мөстәкыйль рәвештә газ белән җылытуга күчә, тагын өч-дүрт елдан бөтен авыл йортларына газ керә...

Шушы ике вакыйга авыр сугыш елларында эвакуацияләнеп килгән заводларны тиз арада япан кырда корып сафка бастыру белән бердәй күз алдына килә... Бу эшнең башында булдыклы, тәвәккәл җитәкче һәм ул сайлап алган кадрлар тора бит... Илбашының кадрлар сәясәте, үз шәкертләрен тәрбияләп үстерү таланты турында китапта аерым хикәяләр дә бар...

Минтимер Шәрип улының үз вазифасын шәкертенә тапшырып, республиканың Дәүләт Киңәшчесе булып эшли башлавына да җиде еллап вакыт узып китте. Бу чор, хатирәләрне яңартып, мемуарлар язып ятар өчен дә бик кулай кебек югыйсә... Юк шул, милләтеңнең, Тукай әйткәнчә, дөнья йөге арбасыннан төшеп калмавы өчен, көн дә ни дә булса эшләргә кирәк. Шагыйрьнең «Хакъкыбыз уртак ватанда шактый ук» дигән шигъри юлы Минтимер аганың төп тормыш девизыдыр, мөгаен. Шулай булмаса, Болгар, Зөя тарихи-архитектура тыюлыкларының колач җитмәс эшләрен колачларга алыныр идемени ул?! 1100 еллар элек ислам динен дәүләт дине итеп кабул кылган Болгар бүген бөтен Евразия киңлекләрендә хак динебезнең мәгънәви мәркәзе булып танылды!

Туган җир, ил-халык, дин, милләт хакын хаклап, җан атып яшәүнең бөек үрнәгедер бу!

*Мөхәммәт Мирза*